**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**«НОВОТРОИЦКИЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»**
**МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕК СОВЕТЫ**

# КАРАР

«20» апрель 2019 ел Новотроицк авыл № 35/1

Татарстан Республиксы Тукай муниципаль районы «Новотроицкий авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советыны 2017 елны 27 октябрендәге 21/2 санлы карары белән расланган «Новотроицкий авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан эшкә алучы (эш бирүче) вәкиленнән коммерциясез оешмалар (сәяси партиядән тыш) белән бер генә кеше идарә итә торган башкарма орган сыйфатында идарә итүдә түләүсез нигездә катнашу яки аларның коллегиаль идарә органнары составына керү өчен рөхсәт алу тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ санлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Новотроицкий авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы,

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Татарстан Республиксы Тукай муниципаль районы «Новотроицкий авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советыны 2017 елны 27 октябрендәге 21/2 санлы карары белән расланган «Новотроицкий авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан эшкә алучы (эш бирүче) вәкиленнән коммерциясез оешмалар (сәяси партиядән тыш) белән бер генә кеше идарә итә торган башкарма орган сыйфатында идарә итүдә түләүсез нигездә катнашу яки аларның коллегиаль идарә органнары составына керү өчен рөхсәт алу тәртибе турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Әлеге Нигезләмәнең 1 өлешен яңа редакциядә бәян итәргә:

«1. «Новотроицкий авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан эшкә алучы (эш бирүче) вәкиленнән коммерциясез оешмалар (сәяси партиядән тыш) белән бер генә кеше идарә итә торган башкарма орган сыйфатында идарә итүдә түләүсез нигездә катнашу яки аларның коллегиаль идарә органнары составына керү өчен рөхсәт алу тәртибе турында әлеге нигезләмә (алга таба – нигезләмә) «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ санлы Федераль законның 14 маддәсе 1 өлеше 3 пункты нигезендә эшләнгән һәм муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан һөнәри союз органы,

шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайлау органы белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашу өчен эшкә алучы (эш бирүче) вәкиленнән рөхсәт алу; съездда (конференциядә) яки башка иҗтимагый оешманы, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативлары, күчемсез милек милекчеләре ширкәтлегене гомуми җыелышында катнашу (алга таба - коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә муниципаль хезмәткәрләрнең катнашуы) процедурасын регламентлый.».

2.Әлеге карарны авыл җирлегендә, мәгълүмати стендларда урнаштырырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасыны рәсми порталында һәм районны рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны законлылык, хокук тәртибе, милли мәсьәләләр һәм халык куркынычсызлыгы буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Новотроицкий авыл җирлеге Башлыгы
Совет Рәисе Р. Р. Волкова